**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 31 март № 182

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында 2016 ел, 17 март, 147 нче карары белән расланган «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында 2016 ел, 17 март, 147 нче карары белән расланган «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программаның II бүлегендә «Барлыгы 9 җәмгыять катнашуы планлаштырыла: «КАМАЗ» ГАҖ төп җәмгыяте һәм 8 бүлендек һәм бәйле җәмгыять («АвтоЗапчасть КАМАЗ» ҖЧҖ, «КАМАЗ лизинг компаниясе» АҖ, «КАМАЗ сәүдә-финанс компаниясе» АҖ, «КАМАЗ тышкы сәүдә компаниясе» АҖ, «КАМАЗ-Энерго» ҖЧҖ, «ПЖДТ-Сервис» ҖЧҖ, «КАМАЗжилбыт» ҖЧҖ, «КАМАЗэнергоремонт» ҖЧҖ)» сүзләрен төшереп калдырыргаъ;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков